МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.05.2018 Казан ш. №218

"Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" конкурсы җиңүчеләренә һәм призерларына грантлар бирү турында шартнамә формасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә" республика конкурсы турында" 2015 елның 1 июнендәге 391 нче карарын гамәлгә ашыру максатларында "Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" конкурсы җиңүчеләренә һәм призерларына грант акчаларын күчерү өчен боерык бирәм:

1. "Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" конкурсы җиңүчеләренә һәм призерларына грантлар бирү турындагы шартнамәнең типлаштырылган формасын 1 нче кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2. Территориаль үсеш идарәсенең муниципаль берәмлекләр үсеше бүлегенә (Э.М.Каргинга) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән "Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" республика конкурсы җиңүчеләренә һәм призерларына грантлар бирү турында шартнамәләрне әзерләргә;

әлеге боерык һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә" республика конкурсы турында" 2015 елның 1 июнендәге 391 нче карары таләпләренә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләреннән хисапларны җыярга.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының "Татарстан Республикасында иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә" конкурсы җиңүчеләренә һәм призерларына грантлар бирү турындагы шартнамә һәм грантларны куллану турында финанс хисабы формаларын раслау турында" 2016 елның 28 октябрендәге боерыгының үз көчен югалтуын танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Н.А.Таркаевага йөкләргә.

**Министр** **Ф .С. Габделганиев**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгына
икътисад министры
урынбасары
14.05.2018 №218

Форма

Шартнамә
"Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе"
конкурсы җиңүчеләренә һәм призерларына грантлар бирү турында

_________ «____» ______ 201_ ел

Бер яктан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сораулары" турында 2007 елның 23 июлендәге 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы турындагы Нигезләмә нигезендә эш алып баручы Татарстан Республикасы икътисад министры Габделганиев Фәрит Солтан улы йөзендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба - Министрлык) һәм икенче яктан ______________________ муниципаль районы (шәһәр округы) Уставы нигезендә эш итүче Башкарма комитет җитәкчесе ____________________ ____________________ йөзендә Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты (алга таба - Вәкаләтле орган), алга таба "Яклар" дип аталып, түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне (алга таба - Шартнамә) төзеде:

I. Шартнамә предметы

1.1. "Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" конкурсы нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле органга түләүсез һәм кире кайтарылмау нигезендә (алга таба - Грант) акчалар күчерелә.

1.2. Грант акчалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында елның иң яхшы үзидарәсе" республика конкурсы турында" 2015 елның 1 июнендәге 391 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә һәм шуңа ярашлы итеп күчерелә.

II. Грантның күләме һәм бирелү шартлары

2.1. БК коды буенча Грантның күләме _________________________________ сум (_____________________________________________________________________________ сум)

2.2. Грант акчалары Вәкаләтле органның Федераль казначылыкның территориаль органнарында ачылган исәп-хисап счетына Шартнамәнең 2.1 пунктында билгеләнгән күләмдә, эш көннәре белән исәпләгәндә, Шартнамә төзелгән көннән башлап 10 көн эчендә күчерелә.

2.3. Грант акчалары Вәкаләтле орган тарафыннан Устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм территориаль иҗтимагый үзидарәнең (алга таба - ТИҮ) социаль мөһим мәсьәләләрен хәл итүгә, ТИҮ рәисе һәм активы эшен бүләкләүгә тотыла.

## III. Министрлыкның хокуклары һәм йөкләмәләре

3.1. Министрлык үзенә түбәндәге йөкләмәләрне ала:

3.1.1. Шартнамәнең II бүлегенә ярашлы рәвештә Грант акчаларын бирүне тәэмин итә;

3.1.2. Шартнамәнең 2.2. пунктына ярашлы рәвештә күрсәтелгән Вәкаләтле орган счетына Грант акчаларын күчерүне тәэмин итә;

3.1.3. Вәкаләтле орган тарафыннан тапшырыла торган документларны тикшерүне башкара;

3.1.4. Вәкаләтле органның Шартнамәгә ярашлы рәвештә үзенә тапшырылган йөкләмәләрен үтәвенә контрольлек итә;

3.1.5. Вәкаләтле орган тарафыннан Шартнамәгә ярашлы рәвештә үзенә тапшырылган йөкләмәләрне бозу фактлары Министрлык тарафыннан билгеләнү яисә дәүләт финанс контроле органыннан әлеге фактлар турында мәгълүмат алыну очракларында, шул исәптән Шартнамәгә ярашлы рәвештә Вәкаләтле орган тарафыннан тапшырыла торган документларда дөрес булмаган мәгълүмат бирелгәндә Вәкаләтле органга Грантны Татарстан Республикасы бюджетына кайтаруны тәэмин итү таләбен (әлеге таләптә күрсәтелгән күләмдә һәм срокларда) юллый.

3.1.6. Вәкаләтле органга Шартнамәне үтәүгә бәйле сораулар буенча аңлатмаларны Шартнамәнең 4.1.2. пунктына ярашлы рәвештә, эш көннәрендә исәпләгәндә, Вәкаләтле органнан мөрәҗәгатьне алу көненнән башлап, 10 көн эчендә юллый.

3.2. Министрлык түбәндәгеләргә хокуклы:

3.2.1. Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Шартнамәнең 2.3. пунктында күрсәтелгәнмаксатларга Грант акчаларының _______ елда тотылмаган өлешен ______ елга юллау ихтыяҗының барлыгы яисә юклыгы турында карарны Грант алучының күрсәтелгән максатларга Грант акчаларының калган өлешен юллау ихтыяҗын нигезләгән документларын алганнан соң биш эш көненнән соңга калмый кабул итәргә;

3.2.2. Вәкаләтле органнан Грант акчаларын куллануга караган финанс яисә башка документларны соратырга;

3.2.3. Вәкаләтле орган тарафыннан алынган Грантны тотуга кагылышлы документлар бирелмәгән очракта, Грант максатчан тотылмаган очракта, һәм шулай ук дөрес булмаган яисә ялган документлар тапшырылган очракларда Шартнамәне вакытыннан алда өзү турында Вәкаләтле органга хәбәр юллау ысулы аша берьяклы тәртиптә Шартнамәне өзәргә.

## IV. Вәкаләтле органның хокуклары һәм йөкләмәләре

4.1. Вәкаләтле орган түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1.1. Грант акчаларын алырга;

4.1.2. Шартнамәне үтәүгә бәйле аңлатмалар алу максатында Министрлыкка

мөрәҗәгать итәргә;

4.1.3. Шартнамәгә ярашлы рәвештә алынган Грант акчаларының 20__ елда кулланылмаган өлешен (ул булганда), Министрлык тарафыннан Шартнамәнең 3.2.1. пунктына ярашлы рәвештә кабул ителгән карар булган очракта, Шартнамәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән максатларга ярашлы түләүләрне башкаруга юлларга.

4.2. Вәкаләтле орган түбәндәге йөкләмәләрне ала:

4.2.1. Грант акчаларын Шартнамәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән чаралар өчен макчатчан һәм нәтиҗәле тотуны тәэмин итә;

4.2.2. Министрлыкның соратып алуы буенча Вәкаләтле орган тарафыннан Шартнамәнең 3.1.4. пунктына ярашлы рәвештә үзенә йөкләнгән бурычларның үтәлешенә контрольлек итүне башкару өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны югарыда аталган соратып алу килгән көннән биш эш көне эчендә юллый;

4.2.3. Шартнамәнең 3.1.5 пунктына ярашлы рәвештә Министрлык таләбе алынган очракта:

4.2.3.1. әлеге таләптә күрсәтелгән срокларда Грант алу тәртибе, максатлары һәм шартларының бозылуы фактларын юкка чыгара;

4.2.3.2. әлеге таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда Грант акчаларын Татарстан Республика бюджетына кайтара;

4.2.4. Шартнамәгә ярашлы рәвештә Министрлыкка бирелә торган мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итә.

4.3. Грант акчаларын максатчан куллануга контрольне башкару максатларында Вәкаләтле орган Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшырырга тиеш:

4.3.1 хисап елыннан соң килүче елның 1 июленә кадәрге срокта Грант акчаларын куллану турында Министрлык тарафыннан расланган, Министрлыкның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mert.tatarstan.ru/) урнаштырылган форма буенча төзелгән финанс хисабын (Шартнамәнең 1 нче Кушымтасына ярашлы рәвештә)

4.3.2. финанслар белән тәэмин ителеше Грант акчалары булган чыгымнар турында хисапны, квартал саен хисап чорыннан соң килүче айның 7 числосына кадәр, Шартнамәнең 2 нче Кушымтасына ярашлы рәвештә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзаланган, чыгымнарны раслаучы документларның күчермәләре белән бергә;

4.3.3. Шартнамәгә ярашлы рәвештә Вәкаләтле орган тарафыннан үзенә тапшырылган йөкләмләрне үтәлешенә контрольлек итү өчен кирәкле мәгълүматны, ул әлеге соратып алу килгән көннән соң биш эш көне эчендә тапшырыла.

4.4. Шартнамәнең 3.2.3. пунктында күрсәтелгән хәбәр алынганнан соң, 60 көн эчендә Вәкаләтле орган Грант суммасын Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтаруны башкарырга тиеш.

## V. Якларның җаваплылыгы

5.1. Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешле дәрәҗәдә үтәмәү өчен Яклар Россия Федерациясе законнарында каралган җаваплылык алып бара.

5.2. Грант өчен каралган акчалар максатчан рәвештә тотылмаганда һәм (яисә) алар буенча дөрес булмаган хисап тапшырылганда, бирелгән акчалар Татарстан

Республикасы бюджетының керем өлешенә 60 көнлек срокта кире кайтарылырга тиеш.

Грант өчен каралаган акчаларны кире кайтару сроклары үтәлмәгәндә, Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланган соң, 30 көн эчендә Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына әлеге акчаларны кире кайтару буенча чаралар күрә.

5.3. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата тотылмаган Грант акчалары агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында кулланылмаган Грантка ихтыяҗ булуы турында Министрлыкның карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы белән килештерелеп, әлеге Грантның тотылмый калган өлешеннән артмаган күләмдә акчалар элегрәк әлеге Грант бирелгән муниципаль берәмлек бюджетының керем өлешенә әлеге Грант бирелү максатларына туры килүче муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен кире кайтарылырга мөмкин.

Грантның тотылмаган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Финанслар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне саклап, Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешенә кайтарылырга тиеш.

5.4. Министрлык, Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары Грантларны түләү өчен билгеләнгән акчаларны бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешенә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тикшерү уздыра.

5.5. Грантларны түләү өчен бирелгән акчаларның максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышына контроль Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә Министрлык тарафыннан башкарыла.

## VI. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Шартнамә имзаланган моменттан үз көченә керә һәм 20_ елның 1 июленә кадәр гамәлдә була.

6.2. Шартнаменең гамәлдә булу срогының тәмамлануы Якларны Шартнамә буенча үзләренә алган йөкләмәләрен үтәүдән азат итми.

6.3. Шартнамәгә кертелгән теләсә кайсы үзгәрешләр, өстәмәләр алар язма формада төзелгәндә һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракта гына гамәлдә санала.

6.4. Шартнамә тарафыннан көйләнмәгән мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә көйләнә.

6.5. Шартнамә вакытыннан алда Якларның килешүе буенча, суд карары буенча яисә Шартнамәдә каралган вазгыять туган очракта өзелергә мөмкин.

6.6. Шартнамәне үтәү барышында туарга мөмкин булган барлык бәхәсләр һәм фикер каршылыклары Яклар тарафыннан сөйләшүләр һәм консультацияләр үткәрү юлы белән хәл ителә.

6.7. Бәхәсләрне сөйләшүләр һәм консультацияләр юлы белән хәл итү мөмкин

булмаганда, бәхәсләр Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә Министрлыкның урнашкан урыны буенча суд карары белән хәл ителә.

6.8. Шартнамә тигез юридик көчкә ия өч төп нөсхәдә язмача төзелә, бер нөсхәсе - Министрлык өчен, берсе - Вәкаләтле орган өчен, тагын берсе - Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы өчен.

VII. Якларның адреслары һәм реквизитлары.

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы:
420021, ТР, Казан ш., Мәскәү ур., 55
Банк Бүлеге - Татарстан Республикасы Милли банкы
Казан ш.
БИК 049205001
к/с -
р/с 40201810900000000002
Алучы: Татарстан Республикасы буенча ФКИ
(Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, ЛБ007020002-МинЭкон))
ИНН 1655141501
КПП 165501001
ОГРН 1071690045129
ОКПО 82318720
ОКВЭД 84.11.21

Вәкаләтле орган:

Татарстан Республикасы
________________________________
муниципаль районы (шәһәр округы)
Башкарма комитеты

Татарстан Республикасы
икътисад министры урынбасары

___________________/Габделганиев Ф.С./

Татарстан Республикасы
____________________________________
______ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты җитәкчесе
________________/___________________/

1 нче Кушымта
Шартнамәгә
___________________201__№

Форма

Расланды
Татарстан Республикасы
икътисад министры урынбасары
___________/___________

**"Татарстан Республикасында**
елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" конкурсы җиңүчесе һәи призеры тарафыннан Грантның кулланылышы турында финанс хисабы

Әлеге хисап белән Вәкаләтле органга Грант бирү турында 20__ елның _______№____ Шартнамә нигезендә күчерелгән Грант акчаларының Устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм территориаль иҗтимагый үзидарәнең (алга таба - ТИҮ) социаль мөһим мәсьәләләрен хәл итүгә, ТИҮ рәисе һәм активы эшен бүләкләүгә тотылуын раслыйм.

| ТИҮ атамасы | Чаралар, үтәлгән эшләр, күрсәтелгән хезмәтләрнең үткәрелү вакыты, урыны һәм катнашучылары (башкаручылары) күрсәтелгән исемлеге | Катнашучылар саны, кеше | Чаралар, эшләр һәм хезмәтләрнең үтәлешен раслаучы документларның атамасы һәм реквизитлары | Барлыгы, шул исәптән бюджеттан тыш акчалар, сумнарда |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | БАРЛЫГЫ: |

Хисапка әлеге хисап мәгълүматларын раслаучы документларның тиешле рәвештә таныкланган күчермәләре һәм __ биттә, ___ данә фотоматериал теркәлә.

**__________муниципаль районы (шәһәр округы)**
Башкарма комитеты - Вәкаләтле орган җитәкчесе

Ф.И.О.: ____________ Имза_________________________
"_______"________________________20___ ел.

**______________муниципаль районы (шәһәр округы) финанс-бюджет палатасы -**
Вәкаләтле органы рәисе:

Ф.И.О.: _____________ Имза____________________________
"_______"________________________20___ ел.

**__________________ муниципаль районы (шәһәр округы)**
ТИҮ җитәкчесе

| № | ТИҮ атамасы | Ф.И.О. | Имза | Дата |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| т/б | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

| Министрлык: | Алучы: |
|---|---|
| ______________/____________________________________/_________________<br>______<br>(имза)     (Ф.И.О) | ____________/________________<br>__<br>(имза)     (Ф.И.О) |

2 нче Кушымта
Шартнамәгә

______________ 201__№

Форма

Расланды
Татарстан Республикасы
икътисад министры урынбасары
___________/___________

Финанслар белән тәэмин ителү чыганагы Грант акчалары булган чыгымнар турында хисап
20___ елның "___"__________

Алучының атамасы ______________________________________________
Кабатлану периоды квартал саен, ел саен
Үлчәү берәмлеге: сум (икенче дистә билгесе төгәллегенә кадәр)

| Күрсәткеч атамасы | Суммасы | | Чыгымнарны башкаруны раслаучы түләү документлары реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | Хисап чоры | Ел башыннан арта бару йомгаклары буенча | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Ел башына Грантның тотылмый калган өлеше, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджетына | | | |
| кайтарылырга тиешлеге расланган ихтыяҗ | | | |
| Кергән акчалар, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджетыннан | | | |
| Чыгымнар буенча түләүләр, барлыгы: | | | |
| шулардан: | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылган, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: штраф санкцияләре куллану нәтиҗәсендә | | | |
| максатчан билгеләнеш буенча тотылмаганнар | | | |
| Хисап чоры ахырына калган Грант акчалары, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: шул ук максатларга юллау таләп ителә | | | |
| кайтарылырга тиеш | | | |

Хисапка түләү документларының тиешле рәвештә таныкланган күчермәләре теркәлә.

Алучы_______________________________________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имза тулысынча)
Башкаручы_____________________________________________________________________________
______
(вазыйфасы) (Ф.И.О) (телефон)
"_______"___________________20___ ел.

| Министрлык: | Алучы: |
| --- | --- |
| ____________/________________________________/______________ ______ (имза) (Ф.И.О) | __________/_____________ __ (имза) (Ф.И.О) |